МИНИСТЕРСТВО
ЛЕСНОГО ХОЗЯЙСТВА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
УРМАН ХУҖАЛЫГЫ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

18.03.2024 № 78-осн

Казан ш.

Татарстан Республикасы территориясендә урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарга һәм аларда булган табигать объектларына китерелгән зыян күләмен исәпләү өчен бәяләрне һәм чыгымнар нормативларын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урманнарга һәм андагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карары нигезендә, Татарстан Республикасы территориясендә урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урман фонды җирләрендә урнашкан урман утыртмаларына һәм аларда булган табигый объектларга китерелгән зыян күләмен исәпләү өчен боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы территориясендә урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарга һәм аларда булган табигать объектларына китерелгән зыян күләмен исәпләү өчен бәяләрне һәм чыгымнар нормативларын кушымта нигезендә расларга.

2. Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга һәм алардагы табигать объектларына китерелгән зыянны каплау үзенчәлекләрен раслау раслау турында» 2018 елның 29 декабрендәге 1730 номерлы карарында билгеләнгән таксалар нигезендә, урман законнары бозылу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыян күләмен чәчкеннәр һәм кәлшәләр үстерүгә, урман культуралары, урман орлыкчылыгы һәм плюс агачларының вегетатив токымнарыннан плантацияләр, табигый шытып чыккан яшь үсентеләрне булдыруга һәм аларны карап тотуга, шытымнарны саклауга, территорияне (агач киселгән урыннарны) кисенте калдыкларыннан, көнкүреш һәм төзелеш калдыкларыннан чистартуга һәм аны алга таба куллану өчен яраклы торышка китерүгә, урман корылышы һәм урман хуҗалыгы билгеләрен ясауга һәм урнаштыруга, урман юлларындагы яки янгынга каршы билгеләнештәге юлларда җитешсезлекләрне бетерүгә, янгынга каршы минераллаштырылган полосалар коруга бәйле чыгымнар күләменнән чыгып исәпләгән очракта, хокук бозу

вакытында гамәлдә булган, әлеге боерыкта билгеләнгән бәяләр һәм чыгым нормативлары кулланыла дип билгеләргә.

3. Урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарда федераль дәүләт урман контролен (күзәтчелеген), урман саклауны гамәлгә ашыручы вазыйфаи затларга урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урманнарга китерелгән зыянның күләмен исәпләгәндә әлеге боерыкка нигезләнеп эш итәргә.

4. Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының «Татарстан Республикасы территориясендә урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарга китерелгән зыянны исәпләү өчен бәяләрне һәм чыгымнар нормативларын раслау турында» 2023 елның 11 апрелендәге 189-осн номерлы боерыгын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Юридик бүлек җитәкчесенә (Т.А.Барсукова) боерык имзаланган көннән башлап эш көннәрендә исәпләнгән өч көнлек чорда аны, дәүләт теркәвенә алу өчен, Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

6. Бу Боерык үтәлешен контрольдә тоту буенча министрның беренче урынбасары И.Н.Зариповны җаваплы итеп билгеләргә.

Министр Р.Ә. Кузюров

Татарстан Республикасы Урман хуҗалыгы министрлыгының 2024 елның 18 мартындагы 78-осн номерлы боерыгы белән расланды

Татарстан Республикасы территориясендә урман законнарын бозу нәтиҗәсендә урман фонды җирләрендә урнашкан урманнарга һәм аларда булган табигать объектларына китерелгән зыян күләмен исәпләү өчен бәяләр һәм чыгымнар нормативлары

| т/с | Эшләр төре | Үлчәү берәмлеге | Күләме | Чыгым-нар, сум |
|---|---|---|---|---|
| 1. | Юкка чыгарылган яки җимерелгән урман төзелеше билгесен әзерләү һәм урнаштыру | данә | 1,0 | 2860,52 |
| 2. | Юкка чыгарылган яки җимерелгән урман хуҗалыгы билгесен әзерләү һәм урнаштыру | данә | 1,0 | 2065,88 |
| 3. | Территорияне (агач киселгән урыннарны) чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы хәлгә китерү | куб.метр | 1,0 | 165,18 |
| 4. | Территорияне (агач киселгән урыннарны) чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы хәлгә китерү | гектар | 1,0 | 6607,33 |
| 5. | Чәчкеннәрне һәм кәлшәләрне 2 елга кадәр үстерү | данә | 1,0 | 3,47 |
| 6. | Чәчкеннәрне һәм кәлшәләрне 3 елга кадәр үстерү | данә | 1,0 | 4,43 |
| 7. | Ябык тамыр системасы белән кәлшәләр үстерү | данә | 1,0 | 19,83 |
| 8. | 3 еллык урман культуралары булдыру | гектар | 1,0 | 114199,52 |
| 9. | 4 еллыктан 5 еллыкка кадәрге урман культуралары булдыру | гектар | 1,0 | 131059,86 |
| 10. | 6 еллыктан 10 еллыкка кадәр урман культуралары булдыру | гектар | 1,0 | 189178,98 |
| 11. | Агач кисү планлаштырылган урыннарда һәм киселгән урыннарда туфрак өслеген минераллаштыру юлы белән урманның табигый торгызылуына булышлык итү | гектар | 1,0 | 3440,29 |
| 12. | Урманның табигый торгызылуына булышлык күрсәтү чаралары белән шытым саклау | гектар | 1,0 | 6305,80 |
| 13. | Урман орлыкчылыгы плантациясе булдыру | гектар | 1,0 | 244594,25 |
| 14. | Урман орлыкчылыгы плантацияләрен карап тоту, карап тотуның һәр елы өчен | гектар | 1,0 | 34338,19 |
| 15. | Территорияне төзелмәләрдән, умарталардан чистарту һәм алга таба файдалану өчен яраклы хәлгә китерү | гектар | 1,0 | 124031,63 |
| 16. | Территорияне коммуналь-көнкүреш һәм сәнәгать калдыклары, көнкүреш һәм төзелеш калдыклары чүп-чарыннан арындыру | куб.метр | 1,0 | 1608,57 |
| 17. | Урман юлындагы җитешсезлекләрне бетерү | км | 1,0 | 43022,63 |
| 18. | Янгынга каршы билгеләнештәге юлдагы җитешсезлекләрне бетерү | км | 1,0 | 35768,33 |